ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районының**
**Красновидово авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**
Кама Тамагы районы,
Красновидово авылы
тел. 8 843 77 2 – 04 - 13

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Исполнительный комитет Красновидовского сельского поселения**
Камско-Устьинский район,
с. Красновидово
тел. 8 843 77 2 – 04 - 13

# КАРАР

**19 сентябрь 2019 ел** **№ 10**

**Җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында”гы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы “Җирле референдум турында”гы Татарстан Республикасы Законының 17 маддәсе, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 15 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР КЫЛА**:

1. “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, авыл җирлеге территориясендә тавыш бирү хокукына ия булган, ташламалы категорияләрдән тыш, 2020 елда 18 яшенә җиткән һәр гражданнан 500 сум күләмендә үзара салым кертергә килешәсезме?

Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- поселок эчендәге һәм урамара юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- суүткәргечләрне һәм су чыганакларын ремонтлау;
- чүп җыю һәм чыгару.

ӘЙЕ ЮК

2. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:
ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Красновидово авылы, Совет урамы, 4 йорт;
ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Бортас авылы, Үзәк урам, 3 йорт;
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Антоновка авылы, Колхоз урамы, 9а йорты, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Красновидово авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **В. П. Оленин**